УДК 792.03

*А.Р. Салихова*

## ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ

В статье рассматриваются основные этапы развития татарского театра.

**Ключевые слова:** татарский театр, история татарского театра, этапы развития.

Татарстанның театр җәмәгатьчелеге Казанда татар телендә рәсми рәвештә беренче театр күрсәтелүнең 110 еллыгын билгеләп үтә. 1906 елның 22 декабре татар театрының туган көне булып санала, аның барлыкка килүе тарихи милли үсеш барышы белән бәйле.

Капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсеше Россия дәүләтенең сәяси, икътисади, рухи сфераларында сизелерлек үзгәрешләр китереп чыгара. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында илнең иҗтимагый тормышы үзенчәлекле динамик үсеш ала һәм ул империядәге төрки халыкларның гадәти көнкүрешенә дә тәэсир итми калмый. Милли капитал арта һәм ныгый, икътисади һәм мәдәни өлкәләрдә татарларның башка халыклар белән элемтәсе көчәя. Яңа, алдынгы фикерле идеология формалаша, милли җәмәгатьчелек институтлары барлыкка килә: сәяси партияләр оеша, матбугат эшчәнлеге киңәя; әдәбият, мәдәният һәм сәнгатьнең дөньяви формалары үсеш ала.

Милли сәхнә иҗатының тууы татар драматугиясе барлыкка килү белән дә бәйле. Беренче татар пьесалары XIX гасырның соңгы чирегендә иҗат ителә. Мәсәлән, 1887 елда Г. Ильясиның «Бәхетсез кыз», 1888 елда Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» пьесалары дөнья күрә. «Чистай комедиясе» (1895) һәм Г. Камалның беренче редакциядәге «Бәхетсез егет» (1898) әсәрләре дә драматургия үсешенең башлангыч чорына карый. Шул ук вакытларда тәрҗемә ителгән (нигездә рус һәм төрек телләреннән) пьесалар да күренә башлый.

Беренче татар спектакльләре байларның шәхси йортларында һәвәскәр түгәрәкләргә йөрүчеләр, шулай ук заманының «Мөхәммәдия» (Казан), «Госмания» һәм «Галия» (Уфа) кебек алдынгы мәдрәсәләрендә укучылар тарафыннан куела. Ә инде 1907 ел башында Оренбургта Россиядә беренче булып мөселман драма актерлары труппасы оеша, аны Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкли. Соңыннан зур танылу яулаган артистлардан Вәли Мортазин-Иманский, Әхмәт Кулалаев, Бари Болгарский һ.б. да иҗади эшчәнлекләрен шушы труппада башлап җибәрәләр. 1907 елның җәендә труппа Идел буе шәһәрләренә беренче гастролен оештыра, анда аларга беренче ха-

тын-кыз актриса Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, аннан Габдулла Кариев кушыла. Репертуарда Ф. Халидинең «Морат Сәлимов», А. Чеховның «Предложение», А. Островскийның «В чужом пиру похмелье» һ.б. әсәрләр була.

Труппа җитәкчесе И. Кудашев-Ашказарский үзе энергияле һәм югары актерлык сәләтенә ия булуына карамастан, аның оештыру һәм киң фикерләү мөмкинлекләре чикле була. Тиздән ул труппаны калдырып, мөстәкыйль иҗат эшчәнлеге башлап җибәрә. Коллектив белән җитәкчелек итүгә яшь, талантлы һәм җаны-тәне белән сәнгатькә бирелгән Габдулла Кариев алына. Г. Кариев киңкырлы шәхес буларак татар сәхнә сәнгатенә шулхәтле көчле йогынты ясый ки, татар милли актерлык мәктәбен әле хәзер дә «Кариевныкы» дип атыйлар. Ул эшен художество җитәкчесе буларак та, режиссер, театр педагогы сыйфатында да алып бара. Шуның белән бергә, труппа эшчәнлеге коллегиаль характерда оештырыла. Коллективның һәр әгъзасы билгеле бер мәсьәләләр өлкәсе өчен җавап бирергә тиеш була: Кариев үзе, мәсәлән, гомуми җитәкчелек, Мортазин белән Гыйззәтуллина – режиссура, Кулалаев – афишаларны язу һәм элү, Хәйретдинов рольләрнең сүзләрен күчереп алу һәм суфлерлык эшен алып баралар. Эшнең мондый бүленеше коллективта дуслык хөкем сөрүгә, үзара ярдәмләшү һәм тигез хокуклы партнерлык турында сөйли.

1908 елның язында татар актерлары Тифлистә гастрольдә булалар һәм алар анда Азәрбайҗан актерлары белән берләшәләр. Бергәләп эшләү өчен репертуарга азәрбайҗан һәм татар драматургларының әсәрләре алына (Н. Наримановның «Надир шаһ», Н. Вәзир-задәнең «Фәхретдин кайгысы» трагедияләре, Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы һ.б.) Ике милләт вәкилләреннән оешкан труппаның эшчәнлеге, аларның һәркайсының иҗади диапазонын да киңәйтә. Татар артистлары, үзләренең азәрбайҗанлы дуслары өчен бик үк таныш булмаган, көнкүрешне яктырткан, психологик реализм белән сугарылган әсәрләр сәхнәләштерәләр, ә үзләре көчле дәртлелек, югары хисләр һәм батырлык пафосы белән сугарылган сәнгать белән якыннан танышалар, күтәренке рухлы романтик манерада уйнау алымнарын үзләштерәләр. Моннан тыш, бергәләп эшләү ике милли труппаның да репертуарларын баета. Шул чордан башлап, Н. Нариманов, М. Ахунов һәм башка азәрбайҗан драматургларының әсәрләре татар театры сәхнәсендә ныклы урын ала.

1908 елгы гастрольләрдән соң бу ике труппа аерылалар. Шуннан башлап, татар труппасы «Сәйяр» («Сәяхәтче») исемен ала. Чыннан да, үз бинасы булмаган коллективка гастрольләр белән күп йөрергә туры килә. Идел буе, Кырым, Кавказ, Урта Азия, Казакстан, Себер – бу төбәкләрнең кайсына гына барып чыксалар да, актерлар үзләренең рәхмәтле тамашачылары белән очрашалар. Ә бит сукбай хәлендәге труппа өчен яшәү шартлары

җиңел булмый, һәм ул аларның иҗади омтылышларын да чикли. Үз биналары булмау, атна саен сәхнәгә яңа пьеса чыгару, бина арендалау, газетада белдерүләр бастыру, афишалар эшләтү зур чыгымнар таләп итә. Матди хәлнең тотрыксызлыгы, әлбәттә инде, беренче татар артистларының эшен катлауландыра. Инкыйлабка кадәрге театр тормышын өйрәнеп тикшеренүчеләр ул чорны милли театр сәнгате үсешенең иң катлаулы этабы дип бәялиләр [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт]. Шуңа да карамастан, театр заманына күрә бик нәтиҗәле эшли. Репертуары жанры һәм стиле буенча төрледән-төрле әсәрләр белән баетыла. Мәсәлән: көнкүреш комедиясе һәм водевильләр; драма һәм көчле трагедияләр; рус, азәрбайҗан, төрек авторларының пьесалары; татар язучылары И. Богданов, Г. Камал, Г. Исхакыйның яңа, көн кадагындагы әсәрләре сәхнәләштерелә. Татар актерларының тормышчан һәм иҗади тәҗрибәләре әнә шулай туплана осталыклары камилләшә, белем дәрәҗәләре киңәя.

1911 елның декабереннән башлап, «Сәйяр» труппасы Көнчыгыш клубның штат расписаниесенә кертелә [Татарча театр]. Ягъни бу – кышкы сезонда иҗади коллективтагы һәркемгә даими рәвештә хезмәт хакы түләнә башлауны, труппа өчен аерым бина бирелүне аңлата.

Шушы вакытта труппага рәссам итеп С. Яхшыбаев алына, ул декорацияләр өчен җавап бирергә тиеш була. Болар барысы да милли театр сәнгате үсешенең икенче этабы башлануны белдерә, ул 1917 елга – иҗади үсеш активлыгы этабына хәтле дәвам итә.

1912 елда Уфада С. Гыйззәтуллина-Волжская җитәкчелегендә икенче профессиональ труппа – «Нур» эшли башлый. Ә 1915 елда Оренбургта В. Мортазин-Иманский тарафыннан «Ширкәт» труппасы оештырыла.

Милли башкарма мәктәп үзенчәлекләре турында әйткәндә, шуны искәртеп үтәргә кирәк: татар актерлары махсус белем алмаган хәлдә дә үз эшләренең пионерлары булдылар һәм профессияләренең нигезен практикада, көндәлек эш процессында үзләштерделәр. Башка труппалар, аерым алганда Казандагы һәм башка шәһәрләрдәге рус театрлары спектакльләреннән үрнәк алдылар, аларның ярдәменә таяндылар. Охшарга тырышу, күчерү алымыннан еш файдаландылар, тормышта сәхнә персонажының реаль прототибын тапсалар, аның һәр кыланышын тулысы белән сәхнәгә күчерделәр. Бу хакта З. Солтанов, Г. Болгарская һәм башка артистларыбызның истәлекләреннән укый алабыз. Иҗади процесска болай якын килү беркатлылык һәм примитив кебек тоелса да, ул сәхнә тормышын башлап җибәрүчеләр өчен зур табыш була, һәм сәхнә реализмы үсешенең билгеле бер баскычын били.

Инкыйлабка кадәрге татар театры төрле кешеләрдән тупланса да, аларның һәркайсы көчле, индивидуаль шәхес була, һәм бу сыйфатлары, берсүзсез, иҗатларында да чагылыш таба. Гомумән алганда, 1917 елгы инкыйлабка кадәр үк татар театры

көчле, талантлы, үзешчән актерлар плеядасын хасил итә, алар өйрәнчекләрчә охшарга тырышудан – мөстәкыйльлеккә һәм тулы канлы иҗатка, образларны бик сай гәүдәләндерүдән – психологик тирәнлеккә, дөреслекне детальләп конкретлаштырудан шигъри һәм социаль гомумиләштерүгә юл салучылар.

Бу юлда стиле, жанры һәм юнәлешләре буенча бай, күп төрле репертуарның да өлеше аз булмый. Бик күп санда рус, төрек, Көнбатыш Европа драмалары татарчага тәрҗемә ителеп сәхнәләштерелә. Милли драматурглар пьесалары нигезендә куелган һәр постановка шатлык белән көтеп алынган вакыйга була. Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, И. Богданов, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек татар драматургларының әсәрләре аеруча зур популярлык казана.

Февраль инкыйлабыннан алып 20 нче еллар башына кадәрге вакыт аралыгында татар театры аеруча нәтиҗәле эшли. Цензура бетерелүдән файдаланып, күптән көтелгән ирек белән канатланган театр элек рөхсәт ителмәгән, кискен темаларны күтәргән әсәрләрне сәхнәгә чыгара башлый. Милли драматургиянең «пролетариат драмасы» дигән яңа жанры үсеш ала. Бер үк сәхнәдә Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Борнаш, К. Тинчурин, Г. Коләхмәтов, Ш. Усманов, М. Фәйзи, Һ. Такташ, Г. Рәхим кебек үзләренең сәяси карашлары һәм иҗади ориентацияләре белән бер-берсеннән бөтенләй аерылып торган язучыларның хезмәтләре сәхнәләштерелә. Бу озын булмаган вакыт эчендә (1917–1923 еллар) татар сәхнәсендә плюрализм хөкем сөрә, дип авыз тутырып әйтә алабыз.

Сәхнә сәнгатенең тасвири чаралары да сизелерлек байый. Бу чорда милли әчтәлекле, романтик рухтагы музыкаль драмаларның сәхнәгә күтәрелүе аерым игътибарга лаек. Мәсәлән: Ф. Борнашның «Таһир – Зөһрә»се (1918), Г. Рәхимнең «Бүз егет»е (1921), К. Әмиринең «Йосыф – Зөләйха» һәм «Ләйлә белән Мәҗнүн» әсәрләре (1922, 1923), Ә. Сәгыйдинең «Сак-Сог»ы (1923) һ.б. Бу постановкаларның кыйммәте шунда, аларның нигезенә чын мәгънәсендә милли халык иҗаты үрнәкләре салынган. Аларны гасырлар тирәнлегеннән килгән Көнчыгыш лирик һәм эпик поэзиясенең традицияләре белән кушып, татарлар өчен әле яңа булган театр формалары тудыру омтылышы да көчәя.

Бер үк вакытта дөнья һәм рус классикасы, аерым алганда трагедия һәм батырлык драмалары кебек, инкыйлаб заманына аваздаш жанрлар белән кызыксыну арта. 1920–1922 елларда Беренче татар дәүләт күрсәтмә труппасы тарафыннан Ф. Шиллерның «Разбойники», В. Шекспирның «Гамлет» һәм «Отелло», Г. Гейненың «Альмансур», Н. Гогольнең «Ревизор», М. Горькийның «На дне» һәм «Мещане» әсәрләре кебек киң танылган пьесалар сәхнәләштерелә. Коллективның җитәкчесе һәм әйдәүче артист Мөхтәр Мутинның иҗади үзенчәлеге бу спектакльләргә бунтарьлык рухы, романтик

күтәренкелек һәм азатлык пафосы өсти.

Октябрьдән соңгы беренче елларда халык массасының һәркайда театр сәнгате белән кызыксынуы көчәя. Бу хакта Б. Гыйззәт болай яза: «Победному шествию Октября сопутствовало создание новых татарских театров в Казани, Самаре, Челябинске, Ташкенте, Бухаре, Хиве, Перми, Семипалатинске, а также крестьянских театров, таких, например, как “Сабанче” в Мамадыше» [Гиззат, с. 338]. Бу елларда үзешчәннәр театрлары киң үсеш ала. Казанда гына да кырыклап профессиональ, ярымпрофессиональ һәм үзешчән коллективлар эшли [Арсланов, с. 97].

Яңа социалистик татар театры идеологиясен иң яхшы чагылдыручы актер, режиссер, драматург Кәрим Тинчурин була. Аның композитор Салих Сәйдәшев белән бергәләп сәхнәгә чыгарган «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе» музыкаль драмалары тамашачылар тарафыннан алкышлап кабул ителә. Монда режиссерның сәхнә формалары өлкәсендәге эзләнүләре дә зур роль уйный. К. Тинчурин спектакльләренә композицияне тыйнакландыру, хәрәкәтләргә бай дәртле ритм, актерларның хискә бирелеп уйнавы, музыкаль бизәлеш, шигъри яңгыраш, биюләр, төрле трюклар хас. Шул ук вакытта ул көнкүреш чынбарлыгындагыча традицион «реализм» формаларын да саклый, режиссер фәкать шул юл белән генә тамашачы күңеленә үтеп керергә мөмкин икәнен аңлап эш итә.

Башка фикерләр дә була. «Суллар сәнгате» тарафдарлары Ә. Мәҗитов, Ф. Саллави, Ф. Бакир һ.б. «искергән» театр алымнарының әһәмиятен тулысынча кире кагалар, алар аны, яңа революцион чынбарлыкны яктыртырга, пролетариат мәнфәгатләренә хезмәт итәргә сәләтле түгел, дип бәялиләр. 1924 елның 24 февралендә «Сулф» иҗади берләшмәсе һәм Ә. Мәҗит җитәкчелегендә «Сулф» драма мастерское оеша. Сул театр эшлеклеләре яңа, тәэсирлерәк театр формалар эзләүне максат итеп куялар, көчле метафорик шартлылыкны, конструктивизмны, иҗатта кыю экспериментларны пропагандалыйлар. Аларның энтузиазмы озакка җитмәсә дә, гадәти булмаган тәҗрибәләре, һичсүзсез, татар театрының сәнгати чаралары палитрасын баета, аның алга таба үсешенә билгеле бер дәрәҗәдә эстетик йогынты ясый.

20 нче елларның икенче яртысында татар театрына махсус театр белеменә ия режисерларның беренче буыны килә. Г. Девишев, Р. Ишморатов, С. Сульва-Вәлиев үз иҗатларында реалистик театрның заман тарафыннан сыналган традицияләрен һәм сәхнә формасы өлкәсендәге табышларны уңышлы кулланалар, сәхнәне техник яктан җиһазландыру чаралары арта (аерым алганда, әйләнә торган сәхнә түгәрәге куелып, актив кулланыла башлый). Спекатакльнең сәхнә бизәлешендә дә сизелерлек үзгәрешләр була: озак еллар рәссам булып эшләгән П. Беньков урынына белеме буенча архитектор булган П. Сперанский билгеләнә. Шун-

нан соң яссылыкка нигезләнгән декорацияләрне сәхнә киңлегендәге архитектур яктан күләмле күренешләр алыштыра. Труппа да яңара: М. Мутин, З. Солтанов, Б. Тарханов, Г. Болгарская, Н. Арапова кебек инкыйлабка кадәрге театр мәктәбе узган, танылган, тәҗрибәле осталар янәшәсендә сәхнәдә яшь, һәрьяктан талантлы артистлардан С. Булатов, М. Вәлишин, С. Айдаров, Г. Кайбицкая, Р. Кушловская, Г. Камскаялар уйный башлый. Репертуар да яңа заман рухындагы әсәрләргә байый. Татар драматурглары революцион идеологияне мавыктыргыч лирик, психологик яктан отылышлы формаларга төреп бирергә өйрәнәләр. Моны сәхнәдә куелган түбәндәге спектакльләрдән күрергә була: А. Таҗетдинов-Рахманкуловның «Килмешәк» һәм «Сафура», Г. Кутуйның «Балдыз», Р. Яхинның «Урман кызы», Г. Минскийның «Мансуровлар гаиләсе», М. Зәетовның «Ханбикә», Ш. Ганиевның «Сүнмәс йолдызлар», Һ. Такташның «Иртәнге матурлык», А. Хәмиднең «Һинд кызы», Ф. Борнашның «Хөсәен мирза» һәм «Адашкан кыз». Сәхнәдә куелган тәрҗемә әсәрләр дә (Р. Лотарның «Шут на троне», Әбү Сәгыйтьнең «Дала кызы», А. Деннери һәм Кермонның «Две сиротки», Б. Лавреневның «Разлом», Д. Фурмановның «Мятеж» һ.б.) зур уңыш белән бара.

30 нчы елларда театр эшчәнлеге өстеннән партия һәм хөкүмәт органнарының контроле көчәя. 1932 елның апрелендә әдәбиятта пролетар төркемнәрне бетерү турында указ чыга. 1934 елда Совет язучыларының беренче съездында әдәбиятта һәм сәнгатьтә социалистик реализм методы бердәнбер дөрес ысул буларак кабул ителә, әмма тора-бара ул башкача фикер йөртүчеләргә каршы көрәштә иң аяусыз коралга әверелә. 1936 елның гыйнварыннан форма һәм стильгә киң масштаблы һөҗүм башлана, нормативлыкка катгый чикләүләр кертелә. Шулай итеп, театр сәнгатенең алгарышка омтылышына киртә куела, яңа формалар эзләү һәм экспериментлар чикләнә.

Мондый сәясәт татар театры өчен зур югалтуларга китерә. Режиссер-новатор Г. Девишев Казаннан китәргә мәҗбүр була, шартлы театр һәм иҗади экспериментлар тарафдары С. Сульва-Вәлиев сәхнә эшчәнлегеннән читләштерелә. «Кыскарту» сәбәбе белән К. Тинчурин, Ш. Шамильский, С. Булатов, Х. Колмәмәт, Г. Уральский һ.б. театрда эшләүдән азат ителә. 1937 елда башланган репрессияләр милли сәнгатьне бөтенләй көчсезләндерә. Яшь театр эшлеклеләре С. Булатов, Г. Исмәгыйльев, Х. Уразиков, Ш. Сарымсаков, К. Тумашева һ.б.ларга сәхнә эшен әнә шундый авыр һәм кысынкылык шартларында башлап җибәрергә туры килә.

Бөек Ватан сугышы театр тормышына тагын бер авыр сынау өсти. Матди чикләнү, кадрларны кыскарту, бинасыз калу (театр бинасы завод карамагына бирелә) – болар театрга килгән кыенлыкларның бер өлеше генә. Театрның репертуар мәсьәләсе кискенләшә, чөнки аның тама-

шачыны җәлеп итәрлек булуы белән бергә заман рухына җавап бирә алу зарурлыгы да калкып чыга. Сәхнәгә дошманның чын йөзен ача торган, совет солдатларының кыюлыгын һәм батырлыгын, тыл хезмәтчәннәренең сабырлыгын һәм фидакярлыгын гәүдәләндергән патриотик рухтагы әсәрләр күтәрелә. Мәсәлән: Ф. Вольфның «Профессор Мамлок», К. Симоновның «Парень нашего города», «Русские люди», Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар», Н. Исәнбәтнең «Мәрьям», Р. Ишморатның «Кайту», Ә. Камалның «Буран», М. Әмирнең «Миңлекамал» әсәрләре. Театрның тарихи үткәннәр белән дә кызыксынуы арта. Н. Исәнбәтнең «Идегәй», Ә. Фәйзинең «Тукай», Б. Горбатовның «Юность отцов» спектакльләре агитацион миссия үтиләр: үз көченә ышанычны, социаль һәм идея ягыннан дошманнан өстен булуны, алда җиңү яуланачагына өметне ныгыталар. Милли классик комедияләрне тамашачылар аеруча яратып кабул итәләр. Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Г. Камалның «Банкрот», Х. Хакимзадә Ниязиның «Мәйсәрәнең шуклыгы», Лопе де Веганың «Собака на сене» кебек көлкеле постановкалары публиканы оптимизм белән сугаралар, сугыш чоры көнкүрешендәге авырлыкларны онытып торырга ярдәм итәләр. В. Бебутов белән К. Тумашева бергәләп сәхнәгә куйган «Король Лир» (В. Шекспир) трагедиясе театр тормышында зур мәдәни вакыйга буларак кабул ителә.

Сугыштан соңгы еллар да татар театры өчен җиңел булмый. Илдә театр белән кызыксыну гомумән бик нык кими. Социаль һәм икътисади сәбәпләрдән (ачлык, җимереклек, халык хуҗалыгын торгызу процессындагы авыр хезмәт) тыш, сәнгать белән коры административ ысуллар ярдәмендә идарә итәргә омтылган партия җитәкчелегенең кырыслыгы һәм урынсыз таләпләре дә театр тормышына үз эзен сала. ВКП(б) Үзәк Комитетының «Драма театрлары репертуары турында», «“Звезда” һәм “Ленинград” журналлары турында», «В. Мураделиның “Великая дружба” операсы турында» дигән карарлары гаять тискәре нәтиҗәләргә китерә. Әдәбиятта һәм театр сәнгатендә урнашкан «конфликтсызлык теориясе, чынбарлыкны артык матурлап күрсәтергә омтылу әсәрләрдән тормыш хакыйкатен, кешеләрне борчый торган көнүзәк проблемаларны куып чыгара. Иҗат иреге дә кискен тыюга дучар ителә. Н. Хрущев җепшеклеге беркадәр иркенлек, саф һава дулкыны алып килә. Татар театрында да җиңелчә лирик комедияләр һәм драмалар куела башлый. Хәй Вахитның сентименталь характердагы әсәрләре буенча Рифкать Бикчәнтәев сәхнәләштергән постановкалар аңа хәтле куелып килгән «идеологик тикшерү узган», «хак», «җитди» спектакльләрдән бик нык аерылып торалар. Аларга да тәнкыйть көчле була, шулай да алар зур уңыш яулый. Тоталитар режим таләпләреннән бераз арына төшкәч, театр, революцион казанышлар белән түгел, ә кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне, мәхәббәт газаплары, әхлакый

проблемаларны якын иткән тамашачыга йөз белән борыла.

Тамашачы мәхәббәтен яулау юнәлешен Марсель Сәлимҗанов та тотып ала. Гомумән, 60 нчы еллар буыны театрның яңа этабын башлап җибәрә. Аренага яшь, иҗади интеллигенциянең актерлар, режиссерлар, композиторлар, язучыларны берләштергән тулы бер плеядасы күтәрелә. Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәенев, Р. Батулла кебек драматурглар, җитештерүне һәм патриотик хисләрне яктыртуда төп игътибарны психологизмга һәм әхлак мәсьәләләренә юнәлтеп, әсәрләрен җанландырып җибәрләр. Әлбәттә, аларның һәркайсының үзәген коммунистик идеология тәшкил итәргә тиеш була, әмма авторларның һәркайсы үз әсәрен я фәлсәфи, я юмор яки мелодраматик күренешләр ярдәмендә баетып, иҗади индивидуальлеген раслый. Театр яңадан популярлык казана, спектакльләр җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята, бәхәсләр темасына әйләнә.

М. Горбачев башлап җибәргән үзгәртеп кору процессы җәмгыятьнең рухи яңарышына этәргеч була. Демократик үзгәрешләр татарларда да үз чагылышын таба. 90 нчы еллар башындагы иҗтимагый борылышлар республикабыз театр тормышында да эзсез калмый: коллективка яңа буын яшь режиссерлар, драматурглар, актерлар, музыкантлар, рәссамнар килә. Театр афишаларында Ф. Бикчәнтәев, Р. Заһидуллин, Р. Әюпов, И. Гыйләҗев, З. Хәким, Г. Каюмов һ.б. исемнәр пәйда була. М. Щепкин исемендәге театр студиясен тәмамлаган бер төркем яшьләр, 60 нчы еллардагы щепкинчы элгәрләре кебек, Г. Камал театрына килеп кушылалар. Шул ук вакытта татар сәхнәсенең танылган осталары яңа шартларда «икенче сулыш» алдылар. Т. Миңнуллин, Ф. Бүләков, И. Юзиев, М. Сәлимҗанов, Н. Исәнбәт иҗатларында яңа темалар күтәрелә башлады.

Борынгы чыганаклар белән кызыксыну омтылышы репрессияләнгән язучылар (Ә. Рахманкулов, Г. Исхакый) әсәрләренә әйләнеп кайту белән генә тәмамланмый, ә яңа пьесалар проблематикасында да чагылыш таба. Әйтик, М. Гыйләҗевнең «Бичура», Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә», «Илгизәр+Вера», Ю. Сафиуллинның «Идегәй», З. Хәкимнең «Күрәзәче» пьесалары. Иҗади һәм милли күтәрелеш Г. Камал театры өчен генә хас күренеш түгел. К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында да җанлы, үзенчәлекле, оригиналь әсәрләр сәхнәләштерелде. Мәсәлән: Н. Гыйматдинованың «Сихерче», Н. Фәттахның «Идел суы ага торыр...» һ.б.

Болардан тыш, дөнья һәм рус классик әсәрләре буенча да тамашачы күңеленә үтеп керердәй спектакльләр куелды. Г. Камал театрында, мәсәлән, В. Шекспирның «Ромео һәм Джулетта», Ибсенның «Өрәкләр», («Привидения»), Лабишның «Станция Шамбоде», Лопе де Веганың «Биюче» («Учитель танцев»), Э. де Филиппоның «Шимбә, якшәмбе, дүшәмбе» («Суббота, воскресенье, понедельник»), Ф. Шиллерның «Юлбасарлар» («Разбойники»),

А. Островскийның «Светит да не греет» күрсәтелде. К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры тамашачылар өчен Г. Лоркның «Кровавая свадьба», П. Бомаршеның «Женитьба Фигаро», Мольерның «Господин Пурсоньяк», Грекованың «Вдовий пароход» әсәрләрен сәхнәләштерде. Болар әле тулы исемлек түгел. Әйтеп үтелгән спектакльләрнең куелыш үзенчәлеге шунда, алар төгәл һәм ачык стилистик чишелешкә ия, тасвири чараларга бай, башкарылу манералары оригиналь, яңа гадәти булмаган образлылык көчле.

Шунысы да мөһим, республикада да, аның чикләреннән тыш та күп кенә татар театры коллективлары оешты. Мәсәлән: Казанда, Яр Чаллыда, Түбән Камада, Уфада, Туймазыда, Оренбургта.... Элек колхоз-совхоз театры буларак эшләп киткән Әлмәт, Минзәлә театрларының да статусы һәм сәнгати дәрәҗәсе нык кына күтәрелде. Республикада югары театраль белем алу мөмкинлеге барлыкка килде. Үзебезнең Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә актерлык-режиссерлык факультетын тәмамлаган белгечләр театрларда, радио һәм телевидениедә эшлиләр. Республикакүләм һәм Халыкара театр фестивальләре уздыру традициягә әйләнде. Чит илләрдә гастрольләрдә булу да хәзер сирәк күренеш түгел. Һәм, ниһаять, спектакльләр кую өчен башка шәһәрләрдән һәм, хәтта, чит илләрдән режиссерлар чакыру мөмкинлеге туды.

Хәзерге вакытта татар театры үз эшен яңа шартларны исәпкә алып оештыра. Ул киләчәккә оптимизм белән карый. Без бүген Илгиз Зәйниев, Дамир Сәмирханов, Резидә Гарипова, Рамил Гәрәев, Альберт Гаффаров, Лилия Әхмәтова кебек яшь режиссерларның исемнәрен зур горурлык белән атыйбыз. Аларның иҗади үсеше өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Һәр ел саен Яшь татар режиссурасы фестивале «Ремесло», ике елга бер мәртәбә театр белеме бирүне киңәйтү максаты белән «Нәүрүз» форумы уздырыла. Шуны да истә тоту мөһим: киңкырлы иҗади үсешкә ия бүгенге буын – калыплашкан традицияләргә генә түгел, ә дөнья күләмендәге заманча сәнгать үрнәкләрендә тәрбияләнгән сәхнә осталары. Алар иҗат процессында төрле формаларны сынап карыйлар, яңа алымнар эзлиләр, гадәти булмаган, кабатланмаган чишелешләр табалар.

Хәзер инде татар театры милли чикләнгәнлек кысаларында эшләми. Чит илләргә гастрольләргә чыгу, халыкара фестивальләрдә катнашу, спектакльләр кую өчен рус һәм чит ил режиссерларын, рәссамнарын, балетмейстерларын чакырып китерү – болар барысы татар театрының сәнгати чаралары диапазонын киңәйтә. Репертуар да баегannан-байый бара: сәхнәгә, рус һәм чит ил драматургиясе генә түгел, прозаик әсәрләр постановкалары да күтәрелә. Мәсәлән: Орхан Памук, Эрих Мария Ремарк, Кобо Абэ романнары буенча. Әлмәт татар дәүләт драма театрында вербатим – реаль кешеләр тарафыннан сөйләнгән чын тормыш тарихын гәүдәләндергән

«Язылмаган язмышлар» спектакле күрсәтелде.

Бер үк вакытта тамашачыны җәлеп итү һәм тәрбияләү буенча да эш алып барыла. Социаль челтәрләрдә махсус сәхифәләр бар, төрледән-төрле реклама акцияләре уздырыла – болар яшьләрне тартуга юнәлдерелгән чаралар. Аларның һәркайсы үз нәтиҗәсен бирә. Ә бу өлкәдә иң мөһиме – яшьләрне кызыксындыра торган, заманча, актуаль темаларны күтәргән спектакльләр үзләре. Шулай ук яшь тамашачыларның игътибарын тартырлык, дулкынландырырлык, зур тәэсир калдырырлык үтемле һәм тасвири сәнгать чаралары да бик мөһим. Татар театры үзенең барлык тарихы дәверендә үз тамашачылары өчен якын һәм кадерле булды. Киләчәктә дә бу традиция сүнмәсен һәм сүрелмәсен иде.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1906–1941). Казань, 1992. С. 97.

*Гиззат Б.* Татарский театр // История советского драматического театра. М.: Наука, 1966. 338.

*Мәхмүтов Х., Илялова И., Гыйззәт В.* Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан, 1988.

Татарча театр // Йолдыз. 1911. 1 ноябрь.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*